Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

**2018 елның 30 ноябре** **29№**

## ФИЗИК ЗАТЛАР МӨЛКӘТЕНӘ САЛЫМ ТУРЫНДА

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәй датасын билгеләү турында» 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советы карар итте:

**1.Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлеге Советы территориясендә физик затлар милкенә мәҗбүри салым билгеләү һәм гамәлгә кертү.**

**2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:**

1) 0,1 процент, карата:

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык төзелешләре яки корылмалары;

«мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары.

Ставка салым түләүчене сайлау буенча бер гаражга яисә машина урынына карата билгеләнә»;

2) 0,2 процент, карата:

фатирлар; фатирлар өлешләре;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент, карата:

торак йортлар; торак йортларның өлешләре;

ике фатирдан торган күпкатлы бер катлы торак йорттагы фатирлар;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент, карата:

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

5) 2 процент, карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китүче салым салу объектлары;

6) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

7) күпфатирлы бер катлы торак йортта ике фатирдан торган фатирга милек хокукына ия физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр күләмендәге салым ставкасының процент өлеше буларак

билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы әлеге фатирга милек хокукында аның өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарыла.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектәге һәр катнашучы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләп чыгарылган салым суммасыннан артып китә алмый.».

**3. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:**

1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган салым түләүчеләр;

2. Әлеге пунктның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләрнең балаларын.

**4. Үз көчен югалткан дип танырга:**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 16 номерлы карарын; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 октябрендәге «Аппак авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 5 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы «Аппак авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»13 номерлы карарын; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 августындагы « Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2018 елның 31 маендагы «Аппак авыл җирлеге Советының 2015 елның 25 маендагы «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 16 номерлы карарын.

4. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Түбән Әлки авыл җирлеге башлыгы: М.Р.Галиуллин